**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 4 июнь № 409

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 ноябрь, 622 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 ноябрь, 622 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 10 декабрь, 706 нчы; 2007 ел, 29 декабрь, 800 нче; 2009 ел, 23 гыйнвар, 35 нче; 2009 ел, 11 декабрь, 849 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 31 гыйнвар, 56 нчы; 2011 ел, 5 март, 177 нче; 2011 ел, 18 ноябрь, 947 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 5 октябрь, 833 нче; 2013 ел, 19 ноябрь, 893 нче; 2014 ел, 21 апрель, 262 нче; 2014 ел, 9 сентябрь, 656 нчы; 2014 ел, 24 декабрь, 1018 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.4 нче пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«капиталь төзелеш объектларын төзекләндергәндә, шул исәптән әлеге объектлар ышанычлылыгының һәм куркынычсызлыгының конструктив һәм башка сыйфатларына кагылышлы төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын саклау эшләрен үткәргәндә, Россия Федерациясе Шәһәр төзү кодексының 49 статьясы нигезендә, капиталь төзелеш объектларын төзекләндерүне, шул исәптән төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын саклау буенча күрсәтелгән эшләрне гамәлгә ашыруга проект

документларына экспертиза (дәүләт яки дәүләтнеке булмаган) үткәрелергә тиеш булса;»;

дүртенче абзацтагы «төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (төбәк әһәмиятендәге яки җирле әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын саклау эшләрен үткәргәндә, әлеге объект ышанычлылыгының һәм куркынычсызлыгының конструктив һәм башка сыйфатларына кагылган очракта);» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Инспекциянең вазыйфаи затлары Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының 9.4, 9.5, 9.5.1 статьялары (капиталь төзелеш объектларын төзүне, төзекләндерүне гамәлгә ашыручы затлар кылган административ хокук бозулар өлешендә), 9.16 статьясының 3 өлеше, 14.28, 14.44 статьялары, 19.5 статьясының 4 өлеше белән күздә тотылган административ хокук бозулар турында эшләрне карарга, шулай ук Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының 6.3, 8.1 статьялары, 19.4 статьясының 1 өлеше, 19.5 статьясының 6 һәм 15 өлешләре, 19.6, 19.7 һәм 19.33 статьялары, 20.4 статьясының 1 – 6.1, 8 өлешләре, 20.25 статьясының 1 өлеше белән күздә тотылган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә хокуклы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\409.doc